Мәмәшир авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2022 елның 29 декабре № 39

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Мәмәшир авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларны үткәрү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлауларны үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылырга, шул исәптән Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырылырга тиеш;

б) 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көннән алып, җирлек халкы гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә яки муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрен, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да Җирлек башлыгына җибәрергә хокуклы.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәрү гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Җирлек башлыгы кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерүне һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерүне оештыра.»;

в) 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, «Бердәм дәүләт һәм

исәптән Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»;

г) 10 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе җирлек Советы тарафыннан раслана торган гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.».

2. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Кукмара шәһәренең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702